**СОВЕТ СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Высокогорский район РТ,
с. Суксу, ул.Школьная, 9а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422729, ТР Биектау районы,
Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9а

Тел./факс: +7(84365) 61-8-43,e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
17 сентябрь 2015 ел № 1

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы "Суыксу авыл җирлеге" Муниципаль берәмлек башлыгын сайлау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясы, Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Уставының 33 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, 41 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Суксу авыл җирлеге Советы регламентына таянып, Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге советына 7 нче номерлы Суыксу сайлау округы депутаты Низамиев Рамил Сәлим улын Суыксу авыл җирлеге башлыгы һәм Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советы рәисе итеп сайларга.
2. «Җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 өлеше һәм Суыксу авыл җирлеге Уставының 41 статьясындагы 5 өлеше нигезендә Низамиев Рамил Сәлим улын Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе итеп билгеләп куярга.
3. Әлеге карар кабул ителгәннән бирле үз көченә керә һәм «Высокогорские вести» газетасында рәсми басылып чыгарга тиеш һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә халыкка җиткерелергә тиеш http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/

Суыксу авыл җирлеге
Совет утырышында Рәислек итүче
3 нче номерлы сайлау округы депутаты Р.Н.Гарипов